**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР № 13**

III чакырылыш XVI утырышы Урыссу ш.т.б. 2019 елның “29” апреле

*2019 елга Ютазы муниципаль районы*

*муниципаль милеген хосусыйлаштыруның*

*Прогноз планын (программасын) раслау турында*

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131 санлы Федераль законның 14 статьясына, 2001 елның 21 декабрендәге “Дәүләт милкен һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 178 санлы Федераль законга һәм 2008 елның 30 маеннан Татарстан Республикасы Ютазы район Советының карары белән расланган “Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы муниципаль милке белән идарә итү һәм аның белән эш итү тәртибе турында”гы Нигезләмәгә, “Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставының 78 маддәсенә ярашлы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Кушымтага ярашлы, 2019 елга Ютазы муниципаль районынының күчемсез муниципаль милеген хосусыйлаштыруның Прогноз планын (программасын) расларга.

2. 2019 елга Ютазы муниципаль районының Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр палатасына “Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең хосусыйлаштыру Прогноз планын (программасын) гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге Ютазы муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:parvo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, регламент һәм җирлек Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Ютазы муниципаль районы Башлыгы –

Ютазы муниципаль районы Советы Рәисе Р. М. Нуриев

**Кушымта**

**Ютазы район Советы карары белән расланды**

**№ _______ “____” ________ 20 ____ел**

**2019 елга “Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге муниципаль милеген ХОСУСЫЙЛАШТЫРУНЫҢ ПРОГНОЗ ПЛАНЫ (ПРОГРАММАСЫ)**

**1 бүлек. 2019 елга муниципаль милекне хосусыйлаштыру бурычлары**

2019 елга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның прогноз планы (программасы) (алга таба текст буенча – Хосусыйлаштыруның прогноз планы) 2001 елның 21 декабрендәге “Дәүләти һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 178 санлы Федераль законга, 2003 елның 6 октябрендәге 131 санлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законга, 2008 елның 22 июнендәге “Россия Федерациясенең дәүләт милкендә яки муниципаль милектә торган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендаланган күчемсез милекне алу үзенчәлекләре, һәм Россия Федерациясенең аерым закончалыклы актларына үзгәрешләр кертү турында”гы 159 санлы Федераль законына, 2008 елның 30 маеннан Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы милке белән идарә итү һәм аның белән эшләү тәртибе турында”гы 115 санлы Нигезләмәсенә яраклаштырып эшләнде.

Базар шартларында формалаштырылган муниципаль милек белән идарә итү системасының бер өлеше буларак, 2019 елда муниципаль милекне хосусыйлаштыруның төп бурычлары булып, ”Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы ” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары функцияләрен һәм бурычларын тәэмин итү өчен файдаланылмаган муниципаль милекне хосусыйлаштыру хисабына муниципаль милек структурасын оптимальләштерү тора, шулай ук “Дәүләти һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында”гы 159 санлы Федераль закон таләпләрен гамәлгә ашыру”, 2008 елның 22 июленнән булган “Россия Федерациясе субъектлары

дәүләти милкендә яки муниципаль милектә торган, һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары арендалаган күчемсез милекне алу үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закончалыклы актларына үзгәрешләр кертү турында”гы 159 санлы Федераль закон таләпләрен гамәлгә ашыру тора.

2019 елда хосусыйлаштыруның төп максатлары булып тора:

- муниципаль милекне хосусыйлаштырудан җирлек бюджетына салым төрендә булмаган табышлар керүен тәэмин итү;

- бюджетның керем өлешен арттыру;

- милекне карап тотуга җирлек бюджетыннан чыгымнарны кыскарту.

Хосусыйлаштыру процессы нәтиҗәсендә “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы ” муниципаль берәмлеге икътисадында структур үзгәрешләр түбәндәге сәбәпләр аркасында көтелми:

-хосусыйлаштыруга куелган торак булмаган бинада, муниципаль берәмлеккә милекче алмашыну нәтиҗәсендә икътисади вазгыятькә сизелерлек тәэсир итәрлек производство урнашмаган.

- "Бөгелмә аграр көллияте" ДБУ филиалы ябылу сәбәпле,  муниципаль район гражданнарының һәм халкының мәгариф өлкәсендә хокуклары бозылмый;

- "Ютазы районы ветеринария берләшмәсе” ДБУ яңа төзелгән бинага күчерелде.

Милекне сату хисабына район бюджетына якынча (ориентировочно) 1.0 миллион сум акча алу планлаштырыла.

Хосусыйлаштыруның прогноз планына ярашлы, сатуга планлаштырылган объектның якынча бәясенә базар бәяләвен уздыргач төгәллек кертү күздә тотыла.

Хосусыйлаштырылырга тиеш булган объектның прогноз бәясе якынча булып тора, ул урнашкан базар конъюктурасыннан чыгып исәпләнде.

2019 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган милекнең исемлеге киләчәктә муниципаль милек структурасын оптимальләштерүне исәпкә алып тулыландырылырга мөмкин.

**II бүлек. 2019 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милке**

| № т/б | объект | адрес | Хосусыйлаштыру ысулы | Күздә тотылган сату срогы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Административ-хуҗалык бинасы (билгеләнеше: торак түгел, 1 кат, тышкы стеналар материалы: башка материаллардан), мәйданы 602,5 кв.м, кадастр № 16:43:080101:118 | Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Ютазы ав., Комсомол ур., 59 йорт | ачык аукцион | **2 квартал** | |
| 2. | Столяр цехы бинасы (билгеләнеше : торак түгел, 1 кат, тышкы стеналар материалы: башка материаллардан), мәйданы 601,7 кв.м, кадастр № 16:43:080101:117 | Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Ютазы ав., Комсомол ур., 59 йорт | Ачык аукцион | **2 квартал** | |